Казан шәһәре Думасының
2024 елның 7 августындагы 12-31 номерлы карары

**Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә территориаль зоналар – табигать территорияләре зонасы (Р1) (80 номерлы контур), рекреация зонасы (Р2) (105 номерлы контур), катнаш торак һәм иҗтимагый төзелеш зонасы (ОЖ) (37 номерлы контур), иҗтимагый-җитештерү объектларын урнаштыру зонасы (ОП) (21 номерлы контур), шәхси һәм блоклап төзелгән торак төзелеше зонасы (Ж1) (147 номерлы контур) чикләрен үзгәртү өлешендә үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 елның 28 гыйнварындагы 63 номерлы карары (2024 елның 24 гыйнварындагы 29 номерлы карар белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) нигезендә, Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең 2022 елның 19 сентябрендәге карарлары нигезендә реестр хатасын бетерү максатыннан Казан шәһәре Думасы **карар бирде**:

1. Казан шәһәре Думасының 2021 елның 16 августындагы 5-8 номерлы карары белән расланган Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә (алга таба – Кагыйдәләр) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. шәһәр төзелешен зоналаштыру (территориаль зоналар) картасында, территориаль зона – иҗтимагый-җитештерү объектларын урнаштыру зонасы (ОП) (21 номерлы контур) чикләренә әлеге карарга 1 номерлы кушымта нигезендә мәйданы 1870 кв.м булган 16:50:050211:200 кадастр номерлы җир кишәрлеген кертеп, территориаль зона – табигать территорияләре зонасы (Р1) (80 номерлы контур) чикләрен үзгәртергә;

1.2. шәһәр төзелешен зоналаштыру (территориаль зоналар) картасында, территориаль зона – шәхси һәм блоклап төзелгән торак төзелеше зонасы (Ж1) (147 номерлы контур) чикләренә әлеге карарга 1 номерлы кушымта нигезендә мәйданы 1658 кв.м булган 16:50:150107:57 кадастр номерлы җир кишәрлеген кертеп, территориаль зона – табигать территорияләре зонасы (Р1) (80 номерлы контур) чикләрен үзгәртергә;

1.3. шәһәр төзелешен зоналаштыру (территориаль зоналар) картасында, территориаль зона – катнаш торак һәм иҗтимагый төзелеш зонасы (ОЖ) (37 номерлы контур) чикләренә әлеге карарга 2 номерлы кушымта нигезендә мәйданы 2210 кв.м булган 16:50:080602:48 кадастр номерлы җир кишәрлеген кертеп, территориаль зона – рекреация зонасы (Р2) (105 номерлы контур) чикләрен үзгәртергә;

1.4. шәһәр төзелешен зоналаштыру (территориаль зоналар) картасында, территориаль зона – рекреация зонасы (Р2) (105 номерлы контур) чикләренә әлеге карарга 2 номерлы кушымта нигезендә мәйданы 2607 кв.м булган 16:50:080602:47 кадастр номерлы җир кишәрлеген кертеп, территориаль зона – катнаш торак һәм иҗтимагый төзелеш зонасы (ОЖ) (37 номерлы контур) чикләрен үзгәртергә;

1.5. әлеге карарның 1.1-1.4 пунктларында күрсәтелгән территориаль зоналарның үзгәрә торган чикләрен Кагыйдәләр составындагы шәһәр төзелешен зоналаштыруның түбәндәге карталарында чагылдырырга:

- шәһәр төзелешен зоналаштыру (территориаль зоналар) картасы;

- территориаль зоналарның ярдәмче зоналары: урам-юл челтәре, табигать-рекреация комплексы, махсус билгеләнештәге яшелләндерү, яр буе территорияләре күрсәтелгән шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы;

- территориаль зоналарның ярдәмче зоналары: территорияне югары интенсивлыкта файдалану, шәһәр төзелешендә әһәмияткә ия территорияләр күрсәтелгән шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы;

- территориаль зоналарның ярдәмче зоналары: тарихи җирлек ярдәмче зонасы күрсәтелгән шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы;

- чикләрендә территорияләрне комплекслы үстерүне гамәлгә ашыру күздә тотыла торган территорияләр картасы;

1.6. Кагыйдәләргә 1 номерлы кушымтаны әлеге карарга 3 номерлы кушымта (хезмәт урынында файдалану өчен) (китерелми) нигезендә территориаль зоналар чикләре урнашу урынының график тасвирламасы белән тулыландырырга;


1.7. Кагыйдәләргә 2 номерлы кушымтаны әлеге карарга 4 номерлы кушымта (хезмәт урынында файдалану өчен) (китерелми) нигезендә территориаль зоналар чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге белән тулыландырырга.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга.

**Шәһәр Мэры** **И.Р.Метшин**

Казан шәһәре Думасының
2024 елның 7 августындагы
12-31 номерлы карарына
1 номерлы кушымта

**Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре составында шәһәр төзелешен зоналаштыру (территориаль зоналар) картасы фрагменты**




**Шартлы билгеләр**

**Р1 - 80**

Территориаль зона контурының тәртип номеры

Территориаль зона индексы


**Территориаль зона**

| **Төс** | **Индекс** | **Территориаль зона төренең атамасы** |
| --- | --- | --- |
| | ОП | Иҗтимагый-җитештерү объектларын урнаштыру зонасы |
| | Ж1 | Шәхси һәм блоклап төзелгән торак төзелеше зонасы |
| | СЗ | Махсус билгеләнештәге объектларны урнаштыру зонасы |
| | С1 | Зиратларны урнаштыру зонасы |
| | | Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре составында шәһәр төзелешен зоналаштыру (территориаль зоналар) картасы фрагменты чикләре |

**Башлыкның беренче урынбасары** **Д.Г.Калинкин**

Казан шәһәре Думасының
<u>2024 елның 7 августындагы</u>
<u>12-31 номерлы</u> карарына
2 номерлы кушымта

**Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре составында шәһәр төзелешен зоналаштыру (территориаль зоналар) картасы фрагменты**




**Шартлы билгеләр**

**ОЖ - 37**

Территориаль зона контурының тәртип номеры

Территориаль зона индексы

**Территориаль зона**

| Төс | Индекс | Территориаль зона төренең атамасы |
|---|---|---|
| | Р2 | Рекреация зонасы |
| | ОЖ | Катнаш торак һәм иҗтимагый төзелеш зонасы |
| | О5 | Спорт объектларын урнаштыру зонасы |
| | | Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре составында шәһәр төзелешен зоналаштыру (территориаль зоналар) картасы фрагменты чикләре |

**Башлыкның беренче урынбасары** **Д.Г.Калинкин**